Казан шәһәре Москаү районы
мәгәриф бүлегенең 286-нче
номерлы балалар бакчасы

# ТАТАР МИЛЛИ КИЕМЕ

## темасына

# ПРОЕКТ ЭШЕ

Казан - 2013

**Максат:** Татар халкының милли кием үрнәкләре белән таныштыру барышында яңа технологияләр кулланып балаларда телгә кызыксындыру уяту.



**Бурычлар:**

1. Балаларны татар халкының милли киемнәре белән таныштыру;
2. Темага караган сүзләрне актив кулланышка кертү;
3. Сөйләм телен үстерү өчен җирлек тудыру.



**Проектны башкардылар**
**Казан шәһәренең Москаү районы**
**балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр:**

- Ахмәтҗәнова Г. Б. – тәрбияче
- Лукоянова М.А. – тәрбияче




**Актуальлеге:** Татар халкының әби-бабайлардан калган гореф-гадәтләрен онытуы, халкыбызның милли киемнәрен белмәве.





Туган илем, туган телем…

Үз илем, үз телем. Бүгенге көндә, кызганычка каршы, үз илендә яшәп тә, үз ана телендә сөйләшә алмаган (әллә теләмәгән?) милләттәшләребезне еш очратырга туры килә. Ә киләчәктә нинди язмыш көтә телебезне? Бөек Тукай теле үзенең бөеклеген саклап калырмы, киләчәк буын гореф гадәтләребезне, йола бәйрәмнәребезне югалтмасмы?




1



2



3



4

Татар теле тәрбиячеләре алдында торган мөһим бурычларның берсе-балаларны халык сәнгатен бәяли белергә, аны яратырга өйрәтү, сәнгать иҗаты буенча кирәкле белем һәм күнекмәләр бирү. Эшне серле, әкиәти, могҗизалы алымнардан башларга кирәк. Балаларны татар халкының милли киемнәре белән таныштыру эшен проект төзүдән башлыйбыз.



## Балаларны татар халкының милли киемнәре белән таныштыру


| Белем бирү өлкәсе | Балаларның эшчәнлек төрләре |
|---|---|
| Коммуника-тив | Татар халык милли киемнәре турында шигырьләр, табышмаклар, мәкальләр туплау. Төрле рәссамчыларның рәсемнәрен карау, курчак турында тасвирлау-хикәя төзү, «Тылсымлы бизәк» альбомы карау, татар халык әкиятләре белән таныштыру. Киемнәрне тасвирлап сөйләү, музейга экскурсия оештыру, экспонатлар карау, музей хезмәткәренең яки тәрбиячененң татар халык киемнәренең үзенчәлекләре турында сөйләве. |
| Әдәби әсәр уку | Татар халкының һәм язучыларның әсәрләре белән таныштыру, шигырьләр өйрәнү, альбомнар карау, әкиятләр уку, милли кием киеп әкиятләрне, шигырьләрне сәхнәләштерү. |

| | |
|---|---|
| Танып белү | Татарстан Республикасының милли музеена бару, сәнгать музеена бару, Г.Тукай музеена экскурсия оештыру, татар рәссамнары һәм аларның иҗаты белән таныштыру, мода журналларын карау. |
| Сынлы сәнгать | Татар халкының сынлы сәнгате белән таныштыру, милли төсләр колориты турында белем бирү, милли орнамент белән кием-салымнарны бизәү, татар орнаментлары мотивларның төрләрен карау. Алъяпкыч бизәү. Рәсем ясау: «Милли киемдәге кыз» яисә «Милли киемдәге малай». Кисеп ябыштыру «Бабайга түбәтәй». Төрле ысуллар белән бизәкләр эвәләү. |
| Хезмәт | Татар халык бизәкләре белән калфак, түбәтәй чигү, татар халык киемнәрен бизәү өчен эскизлар хәзерләү, курчаклар һәм аларга киемнэр хәзерләү. |
| Музыка | Татар халык көйләрен тыңлау, «Ак яулыгым», «Калфагым» җырларын өйрәнү, «Күн читек» җырын җырлау, милли биюләр өйрәнү. Җырлы-биюле уеннар уйнау. |

| | |
|---|---|
| Социальләштерү | Иҗади уен «Ателье», «Тегү фабрикасы», «Алсу кунакка җыена», «Әбидә кунатка», «Татар гаиләсендә бәйрәм», «Киемнәр күргәзмәсе». Дидактик уеннар «Курчакны саф һавага алып чыгабыз», «Курчак белән бәйрәмгә барабыз», «Ак алъяпкыч».<br>Әти-әниләр өчен конкурс «Иң матур күлмәк», «Әбием сандыгы», «Мин иң оста чигүче». |
| Физик культура | «Нәүруз», «Сабантуй», «Сөмбелә» бәйрәме.<br>«Милли киемнәр» парады. |







Проект зур «Сабантуй» бәйрәме белән тәмамлана.





**Нәтиҗә**

Балалар татар халык милли киемнәрен танып белә башлыйлар, киемнәрнең аерым исемнәрен әйтергә өйрәнәләр. Аларда татар халык милли киеме кию теләге уяна. ☺



**Кулланылган әдәбиат**


1. Ф.М.Зиннурова «Үз илемдә, үз телемдә», Мәгариф, 2009
2. Г.З.Гәрәфиева «Сөмбеләне кем белә», Тарих, 2008
3. К.В. Закирова «Мәктәпкәчә тәрбия», Мәгариф, 2007
4. Р.К.Шаехова «Раз словечко, два словечко», Школа, 2002